РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Кармалинского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл жирлеге
Советы

423598, Нижнекамский район,
с. Кармалы,ул. Пионерская,1

423598, Түбән Кама районы,
Кармалы авылы,Пионер урамы, 1

тел./факс (8555) 33-39-17, электронный адрес: Karmalinskoe.sp@tatar.ru, сайт: www.karmalinskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19.03.2020 ел № 10

Кармалы авыл җирлеге
Советының 2018 елның
19 декабрендәге 30 номерлы
«Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлеге
территориясен төзекләндерү
кагыйдәләрен раслау турында»
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кармалы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Кармалы авыл җирлегенең тиешле санитар, янгынга каршы, эстетик торышын һәм анны алга таба төзекләндерүне тәэмин итү максатларында, Кармалы авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Кармалы авыл җирлеге Советының 2018 елның 19 декабрендәге 30 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 статьяда

2.3-2.7, 2.16-2.18, 2.25, 2.26 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әлеге Кагыйдәләрдә кулланыла торган һәм әлеге статьяда күрсәтелмәгән төшенчәләр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында каралган мәгънәләрдә кулланыла».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кармалыавыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

Кармалы авыл җирлеге башлыгы А.Д. Кубышкин